# КОРБАН – рәхмәт һәм бәрәкәт

Казан — 2009

Ихлас

УДК 2
ББК 86.38

*Төзүчесе* ***— Зәйнеддинов Дамирҗан Рөстәмҗан улы,***
*Россия ислам университетының өлкән укытучысы*

# НӘРСӘ УЛ КОРБАН?

Корбанның сүзенең мәгънәсе «якынаю, Аллаһка якынайта торган нәрсә» дип бирелә. Дини терминологиядә исә, ул «билгеле таләпләргә туры килгән хайванны, гыйбадәт нияте белән, ысулына туры китереп чалу» дип билгеләнә. Корбан бәйрәме көннәрендә (беренче өч көндә), бөтен шартын китереп, Аллаһ ризалыгы өчен чалынган малга «удхыййә» (корбанлык) диләр.

## КОРБАН ЧАЛУ КЕМГӘ ТИЕШ?

Бер кешегә Корбан бәйрәме көннәрендә корбан чалу тиеш булсын өчен, анда түбәндәге дүрт шартның булуы зарури:

1. Мөселман булу;
2. Акыллы һәм балигъ булу;
3. Юлчы (мосафир) булмау;
4. Билгеле бер күләмдә малга ия булу;

Хәнәфи мәзһәбендә, корбан чалуны тиешле иткән байлык зәкят һәм фитыр сәдакасы өчен кирәкле булган байлык (нисаб) микъдарына тигез. Бу микъдар исә, бурычлар һәм асыл ихтыяҗлардан тыш, 20 мыскал (85 грамм) алтын яки 200 дирһәм көмешкә тиң. Бу шартларга ия булган хатын-кыз яки үсмерләр шәхсән корбан чалырга тиеш булсалар да, ирләре яки аталары болар исеменнән – һибә юлы белән (путем дарения) – корбан чалса, шул да җитә. Башка мәзһәбләр корбан чалуны сөннәт гамәл дип караганга, аерым бер байлык микъдары билгеләмәгәннәр.

***«Көч-хәле булып та, корбан чалмаган кеше безнең намазгяһыбызга (намаз кылу урыны) якын килмәсен.» (Хәдис Шәриф)***

## КОРБАН ҺӘМ ИГАНӘЧЕЛЕК (ХӘЙРИЯЧЕЛЕК)

Корбан бәйрәмендә укучы-шәкертләргә ярдәм кулы сузу өчен матди-мәгънәви тырышлыктан читтә калмаган мөэминнәр, шул мизгелдә Гарафәттә һәм Мөздәлифәдә булган кешеләрнең әҗеренә тиң, бәлки алардан да артык савапка ирешергә мөмкин. Чөнки хаҗдагыларның тырышлыгы шәхси, боларныкы иҗтимагый; тегендә шәхси камиллеккә ирешү, монда исә милләткә яңадан яшәү рухы өрү мәсьәләсе көн кадагында.

# КОРБАН ТУРЫНДА СОРАУЛАР ҺӘМ ҖАВАПЛАР

**КОРБАН НИ ДИГӘН СҮЗ, АНЫҢ ДИНДӘГЕ ХӨКЕМЕ НИНДИ?**

Корбан – Аллаһка якынаю һәм Аның ризалыгына ирешү нияте белән чалынган хайван дигән сүз. Акыллы, хөр, мокыйм (сәфәрдә булмаган) һәм дини критерийлар буенча бай саналган мөэмин, Аллаһ ризалыгын алу нияте белән корбан чалып һәм Ходайның Үзенә, һәм дә, матди хәлләре авыррак булу сәбәпле, корбан чала алмаганнарга ярдәм итеп, кешеләргә якыная. Күренә ки, бу бәйрәмнең асылында Хак Тәгаләгә якынаю һәм халык файдасына фидакарьлек кылу төшенчәсе ята. Корбан – фикыһтагы (Ислам хокукы) хөкеме нинди булуга карамастан – мөселман җәмгыятьләрнең шигаре (символ) саналган гыйбадәтләрнең берсе булу җәһәтеннән, гомер-гомергә, милләтебез яшәешендә дә әһәмиятле вакыйгаларның берсе булып килгән. Корбан, мөэмин-мөселман бәндәнең, кирәк икән, бар нәрсәсен Аллаһ юлында фида кылырга әзер торуын күрсәтә. Илаһи диннәрнең ахыргысы булган Ислам, бер яктан, аерым-аерым һәр кешене рухи хикмәтләргә һәм күркәм әхлакка ирештерүне күздә тотса, икенче яктан, җәмгыятьләр өчен дә, берләштерү һәм бөтенләштерү көченә ия булган гамәлләр билгеләгән. Ислам диненең ошбу өстен сыйфаты бигрәк тә зәкят, хаҗ һәм корбан кебек социаль юнәлешле малга бәйләнгән гыйбадәтләрдә ачык күренә. Бу гыйбадәтләр Ислам динен тоткан барлык җәмгыятьләрдә, төп принципларын һәм асылын саклган хәлдә, дәвам иткән һәм буыннан-буынга күчә барган.

**КОРБАН КАЙЧАН ЧАЛЫНА?**

Корбан Корбан бәйрәменең беренче, икенче һәм өченче көннәрендә чалына. Шулай да, иң фазыйләтлесе – беренче көнне чалу. Корбан чалу вакыты бәйрәм намазы кылынганнан соң башлана. Корбанны төнлә чалу – тәнзиһән мәкруһ (хупланмый).

**КОРБАНГА ТАВЫК ЯКИ ӘТӘЧ ЧАЛЫРГА БУЛАМЫ?**

Корбанга тавык, әтәч, каз, үрдәк кебек йорт кошларын чалу ярамый. Хәтта боларның берәрсен корбанга чалырга дип нәзер әйткән кеше өстенә бурыч та языла алмый. Чөнки болардан нәзер корбаны була алмый. Бу төр кошлар корбан өчен түгел, ит өчен чалына.

## КОРБАН ЧАЛУ КЕМНӘРГӘ ТИЕШ?

Корбан чалу –

1. акыллы,
2. балигъ,
3. дин критерийлары буенча бай саналырлык малга ия һәм
4. мосафир (юлчы) булмаган мөселманга тиеш.

Асыл ихтыяҗларыннан һәм бурычларыннан кала 20 мыскал (85 грамм) алтын я шул кыйммәттәге акча яки малга ия булган кеше дин күзлегеннән бай санала. Андый кешегә Аллаһ нигъмәтләренә шөкер һәм Аллаһ юлында фидакарьлек галәмәте буларак корбан чалу ваҗиб (тиеш).

## КОРБАННЫ УКУЧЫ ЙОРТЛАРЫНА, ЯТИМХАНӘЛӘРГӘ ҺИБӘ КЫЛУ (БИРҮ) ЯРЫЙМЫ?

Ихтыяҗ булган урыннарга исемеңне атап, бәясен акчалата бирү, һәм корбаныңны алардан чалдыру да дөрес. Хәтта киләчәгебезнең нигезе булган, укучылар тәрбияләнгән йортларга (мәдрәсәләр, интернатларга) корбан акчасын биреп, шунда чалдыру – бик акыллы эш һәм корбанны максималь рәвештә файдалы итеп куллану юлы.

## КОРБАНЛЫК ХАЙВАННЫ ӨЛЕШЛӘП ТҮЛӘҮ БӘРАБӘРЕНӘ (РАССРОЧКА) ЯКИ КРЕДИТ КАРТАСЫНА АЛЫРГА ЯРЫЙМЫ?

Кеше үз милкендә булган һәм корбанлык сыйфатларына ия булган хайванны корбанга чала ала. Шуңа күрә, кирәк вакытында, кирәк өлешләп түләү бәрабәренә, кирәк кредит картасына сатып алынган хайван, кешенең милкенә күчкәнлектән, аны корбанга чалу рөхсәт ителә. Корбанны шәригатьтә тыелмаган юлларның һәркайсыннан сатып алырга була. Өлешләп түләү бәрабәренә (рассрочка) яки кредит картасы белән кылынган алыш-бирешләр рөхсәт ителгәнгә күрә, корбанны да рассрочкага яки кредит картасына алу тыелмый.

## КОРБАНГА ДИГӘН АКЧАНЫ БАШКА МАКСАТКА КУЛЛАНУ ДӨРЕСМЕ?

Корбан гыйбадәте өчен аерып куелган акчаны башка җиргә тоту тыела. Һәр гыйбадәтнең үз урыны бар. Зәкят, фитыр сәдакасы һәм корбан – аерым-аерым гайбадәтләр. Берсе икенчесе хисабына күчми. Шуңа күрә, корбанга дип багышлап бирелгән акчаны башка максатка тотарга ярамый.

**КОРБАН БӘЙРӘМЕННӘН ӘҮВӘЛ, ГАРӘФӘ КӨННЕ НИНДИ КОРБАННАР ЧАЛЫНА?**

Нәфел корбаннар,ваҗиб булган нәзер корбаннар, гарәфә көнен дә кертеп, Корбан бәйрәменә кадәр теләсә кайсы вакытта чалына ала. Удхыййә дип аталган ваҗиб корбан исә фәкать Корбан бәйрәменең әүвәлге өч көнендә генә чалына.

**НИНДИ НӘФЕЛ КОРБАННАР БАР?**

Боларга ваҗиб корбаннардан тыш, нәфел буларак чалынган барлык корбаннар керә. Гакыйка корбаны (бала туу сәбәпле), Ифрад хаҗы (хаҗны гомрәсез кылу) кылганнарның корбаны, Корбан бәйрәменнән тыш чалынган корбаннар, савабы Расүлебезгә (салләллаһү галәйһи вә сәлләм) яки үлгәннәргә багышлап чалынган корбаннар – һәммәсе дә, нәфел корбан категориясенә керә.

**АЛЫНГАН КОРБАНГА СОҢЫННАН БАШКАЛАР УРТАК ИТЕЛӘ АЛАМЫ?**

Мөгезле эре терлекне бер кешедән алып, җиде кешегә кадәр уртак булып корбанга чала алалар. Мондый хайванны җиде кешедән җыелган уртак акчага сатып алып булган кебек, инде алынган яки кулда булган хайванга да, җидедән артмау шарты белән, башкаларны уртак итәргә мөмкин.

**САРЫКНЫ ДА БЕРНИЧӘ КЕШЕ УРТАК БУЛЫП ЧАЛА АЛАЛАРМЫ?**

Сыер белән дөягә җидегә кадәр кеше уртак була алса да, сарык белән кәҗәне бер кеше исеменнән генә чалына. Бу хайваннарда уртаклык рөхсәт ителми. Шунысы мөһим: уртакларның барысында да корбан чалу нияте буларга тиеш. Араларыннан берсе генә булса да, ит алу яки башка берәр ният белән катнашса, барысының да корбаннары яраксызга чыга. Уртаклар арасында гакыйка яки нәзер корбанына ният кылучылар булуы зыянлы түгел. Чөнки алар да корбанга санала. Һәрхәлдә, ниятләре ит алу түгел.

**ХАРАМ (ДИНДӘ ТЫЕЛГАН) ЮЛДАН КЕРГӘН АКЧАГА КОРБАН ЧАЛУ ЯРЫЙМЫ?**

Ислам дине яхшы эшләрдә йөрүне һәм ризыкны хәләл юлдан табуны киңәш итә. Шулай да, әгәр акча харам юлдан кергән һәм аның асыл иясе билгеле икән, бу акчаны иясенә кайтарырга кирәк. Әгәр иясе билгеле булмаса, ниндидер әҗер-савапка өметләнмичә, мохтаҗларга яки хәйрия җәмгыятьләренә тарату тиеш.

Күренә ки, харамнан кергән акчадан корбан чалу хуп күрелми Гыйбадәтләрнең хәләл акчадан булуы шарт. Шулай да, берәр кеше харам акчадан чалган корбаны корбаннан китәр. Ләкин харам табышның гөнаһыннан котылу өчен, бу малны мохтаҗларга яки хәйрия оешмаларына бирү аркылы тизрәк кулдан чыгарырга һәм бүтән андый эшкә кире кайтмаска дип тәүбә кылырга кирәк.

**КОРБАННЫ ЧАЛГАНДА ХАЙВАННЫ МИҢГЕРӘҮЛӘТЕРГӘ БУЛАМЫ?**

Артык җәфаламау максатыннан, бугазлаганчы хайванны миңгерәүләтү, аның корбанлык булуына зыян китерми. Зарурәт булганда, тере килеш чалу шарты белән, корбанлык хайванны, ысулын белеп, миңгерәүләтү тыелмый. Ләкин хайван, шок тәэсирендә, бугазлаганчы ук җанын тапшырса, корбаннан китмәгән кебек, ите дә харам була.

**КОРБАННЫ ХАТЫН-КЫЗ ЧАЛА АЛАМЫ?**

Хайван чалучыдан акыллы, балигъ һәм мөселман булудан тыш, башка шартлар таләп ителми. Ошбу шартларга ия булган кеше кирәк ир-ат, кирәк хатын-кыз булсын, корбан чала ала.

**КОРБАНЛЫК ХАЙВАННЫҢ БӘЯСЕН АНЫҢ ӨЛЕШЕ БЕЛӘН БИРЕП БУЛАМЫ?**

Корбанлык хайван, бәясен исәпләп чыгару максатында, тере килеш үлчәүгә бастырыла ала. Корбан чалу өчен сатып алынган хайванның бәясе, чалынганнан соң, итен үлчәү юлы белән дә билгеләнергә мөмкин. Ләкин кило бәясе төгәл билгеләнергә һәм тире, баш, эчке әгъзаларның кыйммәте, сатучыда кала дип, гомуми бәядән чыгарылмаска тиеш. Шулай ук хайванны чалучы кешегә дә хезмәте өчен корбанның берәр өлешен бирү тыела.

**КОЙРЫГЫ БУЛМАГАН САРЫКЛАРНЫ КОРБАНГА ЧАЛЫРГА БУЛАМЫ?**

Туганда  ук койрыксыз туган яки симез булсын өчен койрыклары киселгән хайваннарны корбан итү тыелмаса да, берәр бәла-каза сәбәпле, кыйммәтен киметер дәрәҗәдә, койрыгының тулысы яки яртыдан күбрәге өзелгән хайванны корбанга чалу рөхсәт ителми.

**КОРБАН ВӘКАЛӘТ БИРЕП (БАШКА КЕШЕГӘ ТАПШЫРЫП) ЧАЛДЫРЫРГА БУЛАМЫ?**

Кеше корбанны үзе чала алган кебек, башка берәүгә вәкаләт биреп тә чалдыра ала. Ник дигәндә, корбан ул – мал белән кылынган гыйба-

дәт. Ә мал гыйбадәтләрендә, мәгълүм булганча, вәкаләт бирү рөхсәт ителә.

Корбан чалырга уйлаган кеше вәкаләтен үзе яшәгән төбәктәге берәүгә бирә алган кебек, башка җирдәге бер кеше яки оешмага да тапшыра ала. Вәкаләт телдән яки язмача, я булмаса телефон, интернет, факс һәм башка шуның кебек элемтә чаралары аркылы да бирелергә мөмкин. Корбан чалган яки вәкаләт биреп чалдырган кешегә, ул иттән авыз итү дигән шарт юк. Бу – мөбаһ гамәл. Шулай итеп, кеше үзе чалган ваҗиб корбан итен дә, гарәфә көнне бугазланган нәфел корбанның итен дә ашый ала, әмма ашамаса, бу корбанның дәрәҗәсен төшерми.

**ГАКЫЙКА КОРБАНЫ НӘРСӘ УЛ?**

Яңа туган бала исеменә шөкер кылу нияте белән чалынган корбан гакыйка дип атала. Гакыйка корбаны чалу – мөстәхәб (хуп күрелә торган) гамәл. Гакыйка итеп чалынасы хайванда башка төр корбанлыкларда булырга тиешле шартлар игътибарга алына. Гакыйка корбанын бала туганнан алып, балигъ булганчы чалу мөмкин булса да, иң фазыйләтлесе – җиденче көнендә чалу. Шул ук көнне балага исем бирү һәм чәчен кыркып, алтыннан шуның авырлыгы бәрабәрендә садака бирү мөстәхәб. Гакыйка корбанының һәм итеннән, һәм тиресеннән, иясен дә кертеп, һәркем файдалана ала.

**ШӨКЕР КОРБАНЫ НӘРСӘ УЛ?**

Тәмәттугъ һәм кыйран хаҗы кылган кешеләрнең, хаҗ вә гомрәне берьюлы үтәп чыгу сәбәпле, чалган корбаннары шөкер корбаны дип атала. Нәкъ шулай ук, кеше берәр максатына ирешү яки берәр нигъмәткә кавышу сәбәпле шөкер корбаны чала ала. Ләкин, нәзер әйтелмәгән булса, максат яки нигъмәткә ирешкән кешегә корбан чалу ваҗиб түгел.

**ЮЛЧЫГА КОРБАН ЧАЛУ ТИЕШМЕ?**

Юлчыга корбан чалу ваҗиб түгел. Әмма чала икән, савабы бар. Сәфәр хәлендә корбан чалган кешеләр, бәйрәм көннәрендә ватаннарына әйләнеп кайтсалар, аларга яңадан бер корбан чалырга кирәк түгел. Сәфәрдә чакта чалмаганнарга, бәйрәм көннәрендә ватаннарына кайтсалар, корбан чалырга кирәк булыр.

**ТӨРБӘЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ТАНТАНАЛАРДА КОРБАН ЧАЛЫРГА ЯРЫЙМЫ?**

Хөрмәтле затларның каберләрен зиярәт кылуда, шул урында Аллаһ Тәгаләгә ялварып дога кылуда бернинди гаеп юк. Элекке заманда шул

ният белән төрбәләрне зиярәт кылган кешеләр, бигрәк тә, хәленнән килгәннәр, зиярәт вакытында корбан чалып, итен фәкыйрь-фокарага таратканнар, ә савабын мәет рухына багышлаганнар. Гореф-гадәт арасына кереп киткән бу гамәл соңгырак дәверләрдә әүвәлге ихласлылыгын җуя төшкән һәм аның эчтәлегенә «фәлән затка корбан чалам» кебек фикерләр кереп оялаган. Мондый фикер исә, мәгълүм булганча, бик хәтәр булып, кешене көферлеккә китерергә мөмкин.

**КОРБАН ТИРЕСЕН НИШЛӘТЕРГӘ?**

Корбан тиресен берәр фәкыйрьгә я булмаса хәйрия оешмасына тапшырырга кирәк. Пәйгамбәребез (с.г.с.) Вәдагъ (Хушлашу) хаҗында, Хәзрәте Галигә, корбанга чалынган дөяләр янында торырга һәм аларның тиреләре белән сыртларындагы җәймәләрен садака итеп бирергә боера. Шулай ук, бу нәрсәләрне чалучыга түләү (хезмәт хакы) итеп бирүдән тыя. (Әбү Давыт; Мәнасик, 20). Күренә ки, корбан тиреләрен акчага сату яки корбан чалучыга хезмәт хакы итеп бирү дөрес түгел.

**НӘЗЕР КОРБАНЫНЫҢ ХАКЫН ФӘКЫЙРЬЛӘРГӘ АКЧАЛАТА ТАРАТЫРГА БУЛАМЫ?**

Берәр гыйбадәтне эшләргә Аллаһка сүз биреп, үз өстенә бурыч алган кеше бу бурычтан котылу өчен нәзерен үтәүдән башка чара юк. Әйтик, корбан чалырга нәзер әйткән кеше, бары корбан чалганнан соң гына нәзерен үтәгән була. Шуңа күрә, нәзер корбаны урынына, акчасын фәкыйрьләргә өләшү яки башка берәр изгелек кылу, нәзер бурычын өстән төшерми.

# ҮЛГӘННӘР РУХЫНА БАГЫШЛАП КОРБАН ЧАЛЫРГА ЯРЫЙМЫ?

Һәркем савабын үлгән берәр туганына яки кадерле кешесенә багышлап корбан чала ала. Кеше дөньядан китеп баргач, аның исеменнән сәдака бирү, хаҗ кылу мөмкин булган кебек, корбан чалу да тыелмый. Сөекле Расүлебезнең (с.г.с.) дә корбан чала алмаганнар өчен корбан чалуы мәгълүм. (Табәрани, Мүгъҗәмүл Кәбир, 3/182; Һәйсәми, Мәҗмәгүз Зәваид, 4/23).

Билгеле булганча, Әбү Давытның «Сөнән»ендә, «Үлгән кеше артыннан корбан чалу» дигән махсус бүлекчәдә түбәндәге хәдис китерелгән:

Хәзрәте Гали (р.г.) ике корбан чалып, шуның берсен Аллаһ Расүленә (с.г.с.) багышлый торган була. Моның сәбәбен сораганнарга: «Аллаһ Расүле (с.г.с.) «үзең исән чакта, минем өчен дә корбан чал», – дип, васыять әйтеп калдырды. Аның бу васыятенә бервакытта да хилафлык китермәм», – дип җавап биргән. (Әбү Давыт, Әдахи, 1; Хәким, Мөстәдрәк, 4/255; Тирмизи, Әдахи).

Пәйгамбәребезнең (с.г.с.) Хәзрәте Галигә «минем өчен корбан чал» дигән васыять әйтүе, аның үз исеменнән корбан чалынганны яратуын күрсәтә. Шуңа күрә, хәленнән килгәннәргә Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.с.) исеменнән һәр ел берәр куй чалу яки корбанлык сыерның җидедә бер өлешенә уртак булу бик тә мактаулы эштер. Аллаһ Тәгалә безләргә пәйгамбәребез (с.г.с.) өчен корбан чалуны насыйп итсен, безне бу хәерле гамәлдә дәвамлы кылып, Үз ризалыгына ирештерсен. Пәйгамбәребезне (с.г.с.) бездән разый әйләсен, әһле бәйтенә, сәхабәләренә, пакь хатын-кызларына Аллаһның рәхмәте һәм сәламе ирешеп торсын. Амин. (Тәханәви, Игълә-үс Сүнән, 17/223).

Бер адәм, үз акчасына алып, савабын берәр үлгән якынына багышлау нияте белән чалган корбанның итен үзе ашый алган кебек, башкаларга да ашата ала. Мондый ният белән чалынган хайванның бәйрәм көннәрендә бугазлануы да шарт түгел. Кайчан чалсаң да була. Хәтта гарәфә көнне чалып, фәкыйрь-фокарага тарату иң яхшысы булса кирәк. Чөнки корбан бәйрәме көннәрендә мохтаҗлар болай да ит белән тәэмин ителәләр. Ә гарәфә көнне чалып, итен таратса, ул көнне дә фәкыйрьләрне куандырган булыр.

Әгәр үлгән кеше үз исеменә корбан чалуны исән чакта васыять итеп калдырган булса, бу корбанны бәйрәм көннәрендә чалырга кирәк. Андый хайванның итен, чалган кешенең үзенә ашарга ярамый. Тулаем сәдака итеп таратырга кирәк. Үлгән шәхеснең васыяте булмыйча, калган акчасыннан алып, чалынган корбан да, васыять нигезендә чалынган корбан кебек. Васыять яки нәзер булмаган очракта да, Шәфигыйлардан кала барча фәкыйһлар фикеренчә, савабын үлеләргә багышлау нияте белән корбан чалу рөхсәт ителә.

Андый корбанның Корбан Бәйрәмендә чалынган башка хайваннардан берниндә аермасы юк.

# КОРБАН ЧАЛУНЫҢ 13 КАГЫЙДӘСЕ

***«Раббың өчен намаз кыл һәм корбан чал!»***
***(Кәүсәр сүрәсе, 2)***

1. Корбан чалынасы урынның чиста-пакь булуы, алдан яхшылап сайлануы зарур.

2. Хайванны чалу урынына рәнҗетмичә, җайлап-иплəп алып килү.

3. Чалганда хайванны кыйбла тарафына каратып, сул ягына яткыру.

4. Ошбу аятьләр хайван бисмилла әйтеп чалынганга кадәр, яки аннан соң укыла:

إِنِّي وَجَّهْتُ وَجْهِيَ لِلَّذِي فَطَرَ السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضَ حَنِيفاً وَمَا أَنَاْ مِنَ الْمُشْرِكِينَ

***«Мин, батыйл диннәрдән ерак торган хәлдә, йөземне күкләрне вә җирне яралткан Галәмнәр Раббысына юнәлттем.»*** (Әнгам сүрәсе, 79 нчы аять)

قُلْ إِنَّ صَلاَتِي وَنُسُكِي وَمَحْيَايَ وَمَمَاتِي لِلّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ
لاَ شَرِيكَ لَهُ وَبِذَلِكَ أُمِرْتُ وَأَنَاْ أَوَّلُ الْمُسْلِمِينَ

***«Әйт: «Минем намазым, һәртөрле гыйбадәтләрем, яшәвем һәм үлемем – барысы да Галәмнәрнең Раббысы хакына. Ише-уртагы юктыр Аның. Миңа бирелгән әмер ошбудыр. Аңа буйсынганнарның тәүгесе мин буламын.»*** (Әнгам сүрәсе, 162-163 нче аятьләр)

5. Бу аятьләр укылганнан соң, дәвам итеп: «Аллаһым! Дустың Ибраһимнән, Хәбибең (Сөеклең) Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләмнән кабул иткән кебек, миннән дә кабул әйлә,» – дип, яки шуңа охшаш бер рәвештә дога кылына. Соңыннан ***Аллаһү Әкбәр, Лә иләһә илләллаһ*** дип тәкбир вә тәһлил китерелә.

6. Корбанны чалган кеше хайванга җәфа китерүдән соң дәрәҗә сакланырга тиеш. Пычакны яхшылап кайрау, хайванга күрсәтмәү мәслихәт.

7. Кыйблага каратып яткырылган хайванны чалганда, пычак уң кулда тотыла һәм ***Бисмилләһи Аллаһү Әкбәр*** дип әйтелә. (Корбан чалучы бугазлау моментында Аллаһ исемен (бисмилла), белә торып, искә алмаса, Хәнәфи мәзһәбе фикеренчә, бу хайванның итен ашау харам).

8. Чалынган хайванга җәфа китермәү өчен, тиресен тунауны, хәрәкәтләре бөтенләй тынганчыга кадәр кичектереп торырга кирәк.

9. Корбан иясенең, корбан чалынган көнне беренче ризыгы итеп, хайванның бавырын сайлавы - күркәм гадәт.

10. Сыер, буйвол, сарык һәм кәҗә кебек хайваннар җиргә яткырылып, аяклары астыннан бугазлана. Дөя исә басып торган хәлдә, алгы сул аягын бәйләп, муенның күкрәккә тоташкан җиреннән чалына.

11. Чалу процессы бугазның ике ягындагы кан тамырларын, аш һәм сулыш юлларын кисүдән гыйбарәт.

12. Хайванның каны чыгып бетсен өчен бер мөддәт көтәргә кирәк.

13. Корбан чалынганнан соң да, чисталык турында онытмаска, хайваннан арткан калдыкларны, тирәнрәк итеп, җиргә күмеп куярга кирәк. Болай эшләү – корбанлык хайванга һәм, тулаем, корбан гыйбадәтенә карата ихтирам билгесе.

# КОРБАННЫҢ ТӨРЛӘРЕ

**Удхыййә (дахиййә):** Билгеләнгән вакытта, дини таләпләргә туры китереп, Аллаһ ризалыгы өчен чалынган, мәгълүм бер хайван. Ислам хокукында һәм халык хәтерендә, корбан диюгә, нәкъ менә Корбан бәйрәмендә гыйбадәт буларак чалынган хайван аңлашыла. Ошбу төр корбан дини терминологиядә удхыййә (дахиййә) дип атала.

**Нәзер корбаны:** Диндә кушылмаса да, кеше Аллаһка нәзер әйтеп, үз өстенә важиб (тиешле) кылган корбан. Бу корбанның итен чалган кешегә, аның балалары һәм ата-анасына ашау тыела.

**Гакыйка корбаны:** Бала туганнан соң, Аллаһка шөкер буларак чалына. Бу корбанның исеме «яңа туган баланың чәче» мәгънәсендәге гарәп сүзеннән килә.

**Мәет рухына багышланган корбан:** Үлгән кеше исеменә чалынган корбан.

**Шөкер корбаны:** Кыйран һәм тәмәттугъ хаҗын кылган кеше чалган корбан.

**Җәза һәм кәффәрәт корбаны:** Хаҗ вә гомрәдә берәр важибне калдыру яки ихрам хәлен бозу очрагында чалынган корбан.

# КОРБАНДА ЯШЕРЕЛГӘН ХИКМӘТЛӘР

**ИБРАҺИМ ПӘЙГАМБӘРНЕҢ УЛЫ ИСМӘГЫЙЛЬНЕ КОРБАН ИТӘРГӘ ТЕЛӘВЕНЕҢ ХИКМӘТЛӘРЕ**

1. Корбан гыйбадәте белән бала мәхәббәтен һәм бөтен сөеклеләрне Аллаһка корбан итү идеалы бирелгән. (Ибраһим һәм Мөхәммәд пәйгамбәрләр үрнәге).

2. Корбан гыйбадәте кеше аңына «үзеңне Аллаһка тапшыру» хакыйкатен сеңдерә.

3. Корбан ярдәмендә кеше үзен символик рәвештә Аллаһка «бүләк иткән» кебек була.

4. Корбан – Аллаһ әмеренә буйсыну һәм туры юлдан бару күрсәткече.

5. Корбан гыйбадәте - Аллаһ тарафыннан Ибраһим Пәйгамбәргә җибәрелгән сынауның дәвамы.

6. Корбан гыйбадәте чын-чынлап ихласлы булырга өйрәтә.

7. Корбан – практик тәүхид дәресе, тәүхид мөгаллиме.

**ИСЛАМ ДИНЕНДӘ КОРБАННЫҢ МӘГЪНӘСЕ ҺӘМ ХИКМӘТЛӘРЕ**

1. Корбан гыйбадәте – Исламның күркәм бер шигаре (символы).

2. Корбан гыйбадәтендә хәер-бәрәкәтләр бар.

3. Корбан гыйбадәте бәндәне Аллаһка якынайта, ул - якынлык символы.

4. Корбан – күптөрле файдалары булган Илаһи бер бүләк.

5. Корбан гыйбадәте – иман һәм коллык галәмәте, дини тормышның күркәм чагылышы.

6. Корбан гыйбадәте – Аллаһны зикер.

7. Корбан гыйбадәте – Аллаһ турында фикер.

8. Корбан гыйбадәте – рәхмәт вә шөкер.

9. Корбан – Аллаһның юмартлыгына каршы колларның тыйнак җавабы.

10. Корбан – Аллаһны сөюеңнең исбаты.

11. Корбан бәхет һәм хозурлык китерә.

12. Корбан – рәхмәт вә бәрәкәт сәбәбе.

13. Корбан – бәла-казаларны кире бора торган калкан.

14. Корбан – Аллаһны олылау, колларга карата шәфкать.

15. Корбан чалган кеше өстендәге дини бурычын төшерә.

16. Корбан гыйбадәте ахирәттә мулдан савап китерә.

17. Корбан, чалырга көче җитмәгән бәндәгә дә савап ирештерә.

18. Корбан гыйбадәте – гөнаһларның кичерелүенә бер сәбәп.

19. Корбаннар ахирәттә ияләренә сират күперен кичәргә ярдәм итәчәк.

## КОРБАН ГЫЙБАДӘТЕНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШКА КАРАГАН ХИКМӘТЛӘРЕ

1. Корбанлыклар – җир йөзендә тәртип вә низам сәбәпчеләре.

2. Корбан гыйбадәте – кешелеккә Аллаһның бик олы бүләге.

3. Корбан - һәркем, бигрәк тә фәкыйрьләр өчен Илаһи сый табыны.

4. Корбан – социаль гаделлеккә ирешүгә хезмәт иткән иҗтимагый бер феномен.

5. Корбан – Исламның кешелеккә ярдәм кулы сузу кампаниясе.

6. Корбан – мөселманнарның сөю-мәхәббәт бүлешүе, шәфкать вә мәрхәмәт күрсәтүе.

7. Корбан гыйбадәте – иҗтимагый хәйрия тәшкилаты.

8. Корбан гыйбадәте гаиләдә вә җәмгыятьтә бердәмлек һәм татулыкны ныгыта.

9. Корбан үпкәләрне оныттыру, күңелләрне табыштыру миссиясен башкара.

10. Корбан – саранлык авыруын дәвалау өчен менә дигән дару.

11. Корбан фәкыйрьләрне пессимистлыктан коткара, язмышка үпкәләү бәласеннән йолып кала.

12. Корбан гыйбадәте күршелек хокукларын җанландыра.

13. Корбан гыйбадәте икътисадны алга җибәрә, аеруча терлекчелек тармагын үстерә.

14. Корбан гыйбадәте – Хак юлында бирелгән олы сәдака.

# Аллаһка бары тәкъвагыз гына ирешер!

Корбанны чалганда да, итен таратканда да Аллаһ ризалыгын күзәтү фарыз. Гыйбадәтләр, хикмәт яки файда дип түгел, фәкать Аллаһ әмере булган өчен генә үтәлә. Шулай да, аларның хикмәт вә файдаларын белү бердән безгә бер вазыйфа булса, икенчедән Аллаһ нигъмәтләрен искә төшерү өчен бер сәбәптер. Исемнәренең берсе Хәким (хикмәт иясе) булган Хак Тәгаләнең һәр эшендә хикмәт барлыгында шөбһә юк. Әмма ошбу хикмәтләрнең барчасын да без коллары аңлап вә төшенеп җитмәскә мөмкин. Хәлбуки, безгә мәгълүм хикмәтләрдән кала, вакыт узган һәм гыйлем-мәгърифәтебез арткан саен, дини әмерләрдә кешелек өчен нинди олуг файдалар сакланганын һәм Аллаһның Үз колларына карата ни дәрәҗәдә мәрхәмәтле вә шәфкатьле булганын күрәбез. Һәм дә хәят (яшәү) нигъмәтенә шөкер буларак корбан чалабыз. Хаҗ сүрәсендә (22/34) әйтелгәнчә, корбан чалудан асыл максат – Аллаһның искә алынуы, ягъни зикер кылынуы. Янә шул ук сүрәнең 37 нче аятендә: «Корбанның ите дә, тиресе дә Аллаһ (хозурына) бармас. Аңа фәкать сезнең тәкъвагыз гына ирешер,» – диган сүзләр аркылы матдәдән мәгънәгә бер капка ачыла һәм асыл максатның ни булуы күрсәтелә.

# КОРБАН ЧАЛМАСКА СӘБӘП ЭЗЛӘМӘГЕЗ!

Җәнабы Хак Кәүсәр сүрәсендә «Раббың өчен намаз торгыз һәм корбан чал,» дип боера. Бу аятьтәге «намаз»дан максат бәйрәм намазы, «чалу»дан морат исә, «нәхр көннәрендә» чалынган хайваннардыр. Башка бер аятьтә исә корбанлык дөяләр хакында: «Корбанлык дөяләрне сезгә Аллаһның шигарьләре иттек», (Хаҗ, 36) диелә. «Шигарь» сүзе Аллаһ диненең галәмәте, ишарәте дигән мәгънәне белдерә. Күп кенә нәрсәләр галәмәт вә ишарәтләренә карап беленә; аларны ташлау һич ярамый.

Шулай булгач, корбан чалмау өчен сәбәп-сылтаулар күзлисе урынга, киресенчә, чалу җаен эзләргә кирәк.

Корбан гыйбадәтен җиренә җиткреп үтәү – Хак юлындагы фидакарьлекнең бер галәмәте; Аллаһ Тәгалә биргән нигъмәтләргә карата колның бер шөкеранасы. Гөнаһларың ярлыкану, әҗер-савапка ирешү, бәла-казадан имин булу чарасы. Кыскасы, корбанның ваҗиблеге бер төркем дини, әхлакый, иҗтимагый файдалар белән раслана. Кадер-кыйммәтен генә белергә кирәк.

# БАЛАЛАРГА КОРБАННЫҢ МӘГЪНӘСЕН АҢЛАТУ

Балалар тормышында бәйрәмнәрнең әһәмияте гаять зур. Бәйрәм көнне өй эчендәге күңелле ыгы-зыгы, өлкәннәр янына барып хәлләрен белү, өйгә килгән кунаклар, бәйрәм табынында туганнар һәм дус-ишләр белән гөрләшеп утырулар, ашалган тәмле-тәмле ашлар – барысы да, татлы хатирәләр булып, кеше хәтерендә гомерлеккә саклана.

Корбанның Рамазан бәйрәменнән аермасы шунда: бу гыйбадәт турында сөйләгәндә үтә дә сак һәм игътибарлы булырга кирәк. Бер җан иясенең Аллаһ ризалыгы хакына гомерен өзү, шул рәвешле, Хак Тәгаләгә якынаерга тырышу кебек мәсьәләләрне, әле үлемнең ни икәнен аңлап җиткермәгән балага төшендерү, чыннан да, дикъкатьлелек таләп итә.

Бу гыйбадәтнең мәгънәсе балага никадәр аңлаешлы һәм тәэсирле итеп төшендерелсә, аның культура үсешенә файдасы шулкадәр зуррак булачак. Шушы уңайдан, иң тәэсирле һәм үтемле аңлату методларының берсе, һичшиксез, хикәя методы.

Аллаһның дусты һәм илчесе Ибраһим Пәйгамбәрнең газиз улын корбан итәргә әмер алуы, бу уңайдан аның күңелендә барган көрәш, улы белән бергәләп Аллаһ ихтыярына тулаем буйсынулары һәм әлеге буйсынуның әҗере сыйфатында Аллаһның куй тәкә иңдерүе хакындагы кыйсса, әле абстракт фикерли алмаган балаларга Корбан бәйрәмен котлау куанычын тирәнтен тоярга ярдәм итә. Бу кыйсса Илаһи диннәрнең барысы өчен дә уртак булу җәһәтеннән, динара диалог коруның да нигезен тәшкил итә.

Корбан, билгеле форма аермалыклары булса да, Илаһи диннәрнең барысында да мәгълүм булган, колның Яралтучысына якын килүен символлаштырган гыйбадәт. Хәтта Илаһи нигезгә корылмаган диннәрдә дә, корбан китерүнең төрле примитив формалары яшәп килә. Изге китабыбыз Коръәндә исә, корбан кирәк хаҗ гыйбадәте эчендә, кирәк Ибраһим Пәйгамбәр кыйссасында урын алган олы гыйбадәт булып күз алдына килеп баса. Чалынган корбанның ите дә, каны да Аллаһка ирешмәвен, асылда Хак Тәгаләнең моның кебек нәрсәләргә мохтаҗ да булмавын истә тотып, фәкать Аллаһ ризалыгына ирешүне генә максат итеп тоткан гыйбадәт ул корбан. Безнең карамакка тапшырылган бар нәрсәнең, чынлык-

та Аллаһныкы булуын аңлап, Аның ризалыгы өчен һәммәсен дә фида кылырга риза булуыбызны күрсәтү идеясенә корылган гыйбадәт.

Шулай да, бала бу темага кагылышлы сораулар биргән очракта, җавапны аның рухына, күңеленә һәм мантыйгына туры килерлек итеп бирү шарт. Артык детальләргә кереп тормыйча, кыска, җыйнак кына аңлатма бирергә, мөмкин булса, берәр мисал да китерергә кирәк. Корбан чалу процессы төрле балага төрлечә тәэсир итә. Артык дулкынланудан, беренче көнне ит ашый алмаган балалар булган кебек, моны бик тыныч кабул итеп, хайванны кызгану хисен саклаган хәлдә, итен рәхәтләнеп ашаган реалист балалар да бар. Шулай ук, кайбер балаларда биологиягә карата гаҗәеп дәрәҗәдә кызыксыну күзәтелә. Хайваннарны бик яратса да, үлем күренешен бик мантыйклы рәвештә кабул итеп, корбанлыкның тән төзелешен тикшергән, органнарын танырга тырышкан, аларны үзенең тән әгъзалары белән чагыштырырга омтылган балалар бар. Андыйларның алдагы тормышларында биологиягә мөнәсәбәтле өлкәләрдә зур казанышларга ирешү фактлары бихисап.

Корбан мәсьәләсендә баланың яше һәм психологиясен һәрвакыт күз уңында тоту; үзе карап, иркәләп үстергән хайванны корбан итәргә кушу кебек, сабый йөрәгенә җәрәхәт ясарлык эшләрдән ерак тору мәслихәт. Мондый дуамал кыланышлар кайбер балаларның психикасын травмалау өчен җитә кала.

Бала корбан гыйбадәтенең мәгънәсен тагын да тирәнрәк аңласын, бу аның табигатенә сеңсен дисәк, яше барган саен, аны бик күп нәрсәләрдән хәбәрдар итә барырга кирәк. Менә аларның кайберләре:

Дөньяга килүнең сәбәп вә максаты, яшәү һәм үлемнең мәгънәсе, Илаһи диннәрнең бер-бер артлы килү хикмәте, тарихи процесслар, кешелекнең үсеше, җанлылар дөньясы, җан ияләренең бер-берсенә мохтаҗ булуы, табигатьтәге камил баланс һәм гармония, терлек үрчетүнең нигә кирәклеге, сәламәтлек һәм сәламәт яшәү өчен кирәкле туклану матдәләре, хайваннар белән дус булу, аларны рәнҗетмәү, имтихан дөньясында булуыбызны онытмау, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, ярдәмләшү һ.б.

Күренә ки, корбан гыйбадәте, барча гыйбадәтләр кебек үк, күпкырлы феномен булып, пакь табигатьләре дини тәрбия алуга соң дәрәҗәдә ятышлы булган балаларның үсеш-камилләшү процессында зиһеннәрен ачарга һәм мотивацияләрен арттырырга мөмкинлек бирә.

# ИСМӘГЫЙЛЕҢНЕ КОРБАН ИТ!..

***Исмәгыйлеңне Корбан Ит!..***
***«Күз нурыңны Аллаһка корбан ит!..»***

Бу әмер шәфкатьле пәйгамбәр һәм мәрхәмәтле ата Хәзрәте Ибраһим галәйһиссәламгә бирелә. Күп еллар элек әйтелгән «улым булса, аны Хак Тәгаләгә корбан итәр идем» сүзе, инде менә төшендә искәртелеп, аңа вәгъдәсен үтәү вакыты җиткәнлеге белдерелә.

Ибраһим пәйгамбәрнең күңеле шул дәрәҗәдә нечкә ки, Җәнабы Хак аны: «Ибраһим, дөрестән дә, бик хисле, олы җанлы, йомшак кальбле һәм үзен Аллаһка багышлаган кеше иде,» – дип сыйфатлый. Һәрдаим аһ орып, зарый кылган, күзендә яше кипмәгән, мәрхәмәте киң, мәхәббәт вә шәфкате чиксез булган шушы Хак илчесе «Исмәгыйлеңне корбан ит!..» дигән әмер ала.

Михнәт вә мәшәкатьтә узган гасыр тиңентен гомерендә, тәүхид мөәззине булып, ширек баганаларын берәм-берәм аударган; үзеннән соң кешеләргә юл күрсәтәчәк хәерле варис, күз нуры булырдай, игелекле бала сорап ялварган; инде чәч-сакалына бәс кунган көннәрдә, ниһаять, гомеренең нәтиҗәсе, кешелек агачының «асыл җимеш»енә орлык булачак йөрәк парәсен тапкан ата һәм, яңа ачылган бөредәй, угыл...

Шундый бер угыл ки, атасы аның килүен йөз ел көткән, ул исә атасы һич көтмәгән бер мизгелдә килгән; килгән һәм Ибраһимның, үз җанындай кадерләгән, бүз егете, яшәү өмете, күңелен мәхәббәт һәм рухи ләззәткә кинәндергән мөбарәк бер үсенте булып киткән.

«Ибраһим! Пычакны улыңның муенына терә һәм аны үз кулларың белән корбан ит!»

Менә шушы коточкыч хәбәр Аллаһның Хәлилен үз гомерендә, бәлки тәүге мәртәбә тетрәткән, куркуга салган... Кайсын сайларсың, әй Ибраһим?

Әсирлекнеме, котылунымы? Хисеңнеме, акыл-аңнымы? Күңел багыңнымы, Илаһи фәрманнымы? Аталыгыңнымы, пәйгамбәрлекнеме? Аталык шәфкатенме, нәбилек җитдиятенеме? Исмәгыйльнеме, Хак Тәңренеме?

Сайла, әй Ибраһим!

Бердәнбер күңел җимешеңне, бәгырь кисәгеңне, яшәү сәбәбеңне,

сине бу дөнья тормышына бәйләгән һәм бу йортта тотып торган бар нәрсәңне... Улыңны, юк, дөресрәге Исмәгыйлеңне, корбанлык куй кебек, тотып җиргә яткыр, яткыр да, кис муен тамырын... Бу хәлне күреп йөрәк телгәләнә, бу сәхнәгә карап күзгә яшьләр тыгыла.. Атада төшен сөйләрлек көч-дәрман калмаган. Рухының иңрәү авазларын көйләрлек сулышлар да өзлеккән. «Миңа сине корбан итәргә боерылды» дигән сүз үзе үк аны сискәндерә. Ниятен ачарга теләп кабат-кабат талпынып карый ул, тик «Исмәгыйль» диюгә теле тотлыга; бераз тынычлана төшкәч, кыюланып, янә баласына сүз әйтергә була, ләкин бу юлы да очын-очка ялгый алмый интегә. Ниһаять, кальбен Аллаһка тапшырып, җан-фәрманга күңелендәге төерне чишә:

«Бер төш күрдем, балам. Имеш, сине бугазларга, корбан итәргә торамын икән. Я, ни дисең бу эшкә!?»

Исмәгыйль эшнең нидә икәнен аңлап ала. Әтисенең сагышлы йөзенә яратып бер карый, күңел газабын күреп кызгана һәм юатырга ашыга: «Әткәем! Озак уйлап торма, Хак Тәгаләнең әмерен үтәүдә икеләнмә. Буйсын Раббыңа, сиңа Аллаһ тарафыннан ни боерылган булса, шуны эшлә. Иншаллаһ, минем дә сабырлы, чыдам булуымны күрерсең!» – ди.

Җанын Аллаһ юлында бирер өчен муенын пычак астына куя алган егет...

Аллаһ әмеренә буйсыну кирәклеген тулысынча аңлаган һәм Хак Тәгаләгә корбан китүне дастанга әверелдергән тәүхид каһарманы. Исмәгыйль.

Хак Тәгаләнең фәрманын кабул итүдә үзен шулкадәр күндәм һәм ипле тота ки, әйтерсең 12 яшьлек үсмер түгел, ә «бик сабырлы бер корбан».

Йөрәге шәфкать һәм мәрхәмәт белән типкән Хәлил (Ибраһим пәйгамбәрнең кушаматы), башта Илаһи мәхәббәттән рухына иңгән көч ярдәмендә, үз эчендә үзен үтерә, үзенең җан тамырын кисә. Эче үз «минлегеннән» бушап калгач, күңелен Аллаһ тутыра. Шул мизгелдә ул бары «Һу» («Ул» — Аллаһыга ишарәт кыла торган алмашлык) дип сулаган бер җан иясенә әверелә.

Икесе дә Аллаһ әмеренә буйсынган. Ибраһим улының чигәсен җиргә тери; тиз һәм җайлы киссен дә, бәгыркәенә авырту китермәсен дип, әүвәле кулындагы пычагын яхшылап кайрап, ташка кизәнә. булды, үткен пәке ташны да икегә яра..

Әмма, ни гаҗәп, таш булып ташны да телгән пычак, нәфис муенга үтми...

Бу пычак кисми...

Шулчак, бер тәкә һәм Илаһи фәрман:

«Әй Ибраһим! Син төшеңә тугры калып, кирәклесен эшләдең, вазыйфаңны үтәп чыктың; Аллаһ исә, Исмәгыйль урынына чалырга дип, ошбу куй тәкәне җибәрде. Менә шулай бүләклибез Без игелек вә ихсан ияләрен!»

Дөрестән дә, Аллаһ Тәгалә һичкайчан Исмәгыйль(ләр)нең канын сорамый, Аның корбанга ихтыяҗы да юк. Чалынган корбанлыклардан максат аларның ите һәм каны да түгел. Рахман вә Рахим булган Аллаһ, Ибраһимны «Исмәгыйлен корбан итү биеклегенә менгерә»; әмма бу текә кыяны аңа Исмәгыйльне корбан иттермичә генә «буйсындыра». Ибраһимның оныкларыннан да ит һәм кан түгел, ниятләрендәге ихласлык һәм тәкъва сорала.

Бәс, аң бул, әй бу чорның Ибраһимы.. Бүген «корбан» китерү чираты синдә.

Ә синең Исмәгыйлең кем яки нәрсә?

«Кәнәфи»еңме, шәрәфеңме, дәрәҗәңме, карьераңмы, сөйгән ярыңмы? Акчаң, йорт-җирең, бакчаң, белемең, эшең я чибәрлегеңме? Юкса, нәфесең, «мин-минлегең», «үзем»еңме?

Әйттем ич инде сиңа, Ибраһим өчен Исмәгыйль бер атаның улы гына түгел:

Михнәт-газапта үткән гомернең мөрәүвәте, ачы хәсрәт тулы гасырның әҗере, мәшәкатьтә узган тормышның җимеше, карт атаның куанычы, йөз еллар үткәч киләчәк Мәдинә Гөленең гонҗәсе (ачылмаган чәчәк), бер пәйгамбәрнең нәбилек белән шәрәфләндереләчәк мәхдүме була. Ибраһимнең Исмәгыйле улы була, ул үз улын корбан итә. Синең Исмәгыйлең бәлки «үзең», бәлки «гаиләң», эшең, байлыгың, шәрәфең.. Исмәгыйль исемендәге җаның, җанашың, ашың, эш хакың...

Сине фазыйләтле, абруйлы, хөрмәткә лаек кеше итәсенә ышанган, аны кулга төшерү яки югалтмау хакына барча яхшылык һәм гүзәллекләрне дә фида кылырга әзер булган күңел кыйпылчыгың, менә синең Исмәгыйлең. Ул берәр шәхес тә, мал да.. дәрәҗә, урын, хәтта «зәгыйфь нокта» да булырга мөмкин.

Ташла икеләнүләр, юраулар, ихтималлар белән юануны. Җаваплылыктан качма, үзеңне җаваплы итеп тот. Нәфесеңне, үз җаныңны корбан итәргә әзерлә рухыңны, шәт бөтен Исмәгыйльләр котылсын. Исмәгыйльләр урынына «мин»не чал.

Әй нәфсем,

Кил, әйдә, син дә корбан ит теләкләреңне, дөньяви таләпләреңне һәм Хак Тәгаләгә илтмәгән, Аны искә төшермәгән һәр нәрсәне. Хәзрәте Ибраһим вазыйфа җаваплылыгын аталык шәфкатеннән өстен куйган, син дә Хак юлында хезмәт итүне бөтен теләкләреңнән алгарак куй; аларны идеяңә корбан ит, юк икән, фидакарьлек, Аның юлында корбан булу турында лаф орма, зинһар.

# КЫСКАЧА

## 1. КОРБАН - ТӘСЛИМИЯТ

Корбан – тәслимият[1] символы. Ислам сүзе үзе үк тәслимият мәгънәсен белдерә. «Һәр икесе дә (Ибраһим һәм Исмәгыйль) тәслим булгач һәм Ибраһим (галәйһиссәлам) угылын йөзтүбән яткыргач...» (Саффәт, 23) аятендә бала мәхәббәтенең Аллаһка буйсыну өчен киртә булмавын күрәбез. Бу гамәле белән ул бөек пәйгамбәр гүяки: «Әгәр әмер булса, Исмәгыйлемне генә түгел, үземне дә корбан итәр идем,» – дип, чиксез тәслимиятен исбат итә. Димәк ки, андагы иман бөеклеге тәслимиятнең менә шундыен таләп итә. Ошбу тәслимиятнең иң саф һәм эчкерсез рәвештә күренгән урыннарының берсе, һичшиксез, корбандыр.

## 2. КОРБАН – ТУГРЫЛЫК ГАЛӘМӘТЕ

Хәзрәте Ибраһимның Аллаһка тугрылыгы һәм Исмәгыйль галәйһиссәламнең Аллаһы хакына атасына тугрылыгы. Безләр ошбу тугрылык дастаннарын үрнәк алып, Бөек Раббыбызга карата тугрылык һәм вафалыгыбызны күрсәтергә тиешбез. Корбан Аллаһның әмере һәм Сөекле Расүленең сөннәте булганга күрә, малыбыздан сәдака һәм иманыбызда тугрылык күрсәткече буларак, корбан чалырга, бер үк вакытта корбанның ни-нәрсә икәнен онытып җибәргәннәргә тугрылык һәм вафа юлын яктыртырга бурычлыбыз.

## 3. КОРБАН – ЮМАРТЛЫК

Артык сүз һәм комментарийга кермичә, Аллаһның әмерләре каршында Ибраһимдай баш ию кирәк. Аның юлында малыбызны, хәтта кирәк икән, җаныбызны да фида кыла алу, «бир!» дигәндә, «Аллаһ хакы өчен бирәм» дип, бирү бик мөһим. Бу мәсьәләдә аз гына саранлану да иманыбызга һәм Ислам дәгъвасына зыян китерәчәк. Шулай итеп, корбан ул – мөэминнең малы белән үзен Аллаһка багышлаган булуының күрсәткече. Аллаһ «Корбан чал» дип боерган вакытта, мөселман бәндә саранланмыйча, «Я Раббым, Син кушсаң, мин берне генә түгел, меңне чалырга әзермен,» – дип әйтә белергә тиеш. Бу эштә безгә иң камил үрнәк - Пәйгамбәребездер (салләллаһү галәйһи вә сәлләм). Чөнки ул гомеренең соңгы корбанында үз яше бәрабәрендә, ягъни нәкъ алтмыш өч корбан чалган. Бүген дә хәлле кешеләребез зур-зур байлыклары

[1] Аллаһ әмеренә тулысынча баш ию, камил буйсыну, итагать.

бәрабәренә, теләнчегә кесәдән берничә тиен чыгарып биргән кебек, бер генә корбан белән чикләнмәскә тиешләр. Бәлки үзе һәм бала-чагалары бер корбанга канәгать китереп, фәкыйрь-фокарага аерым, киләчәгебезне нурландырачак яңа нәсел үсеп җитсен өчен аерым, дус-иш һәм туганнарга атап аерым бирәр корбан чалу, Җәнабы Хакның ризалыгына ирешү юлында мөһим адым булачак. Аллаһ Расүле (салләллаһү галәйһи вә сәлләм) корбан итенең өчтән бер өлешен генә үзеңә калдырып, өчтән берен мохтаҗларга, калган өчтән берен исә күрше-күлән, дус-иш һәм туган-тумачага таратуны киңәш итеп, корбан чалудагы хикмәтләрнең берсе юмартлык һәм игелеклелек хисләребезне тергезеп җибәрү икәнен күрсәткән. Шулай булгач, хәленнән килгән кешеләр нигә бер генә корбан белән чикләнергә тиеш ди әле?..

**4. КОРБАН - ФИДАКАРЬЛЕК**

Исмәгыйль галәйһиссәламне корбан итәргә алып бару, Аллаһ хакына корбан итеп булмаслык нәрсә юклыгын исбат итә. Мондый олы фидакарьлек Хәниф Пәйгамбәр Хәзрәте Ибраһим тарафыннан кылынгач, Аллаһ гүя: «Менә хәзер булды, әй Ибраһим! Исмәгыйльне бугазлауга хаҗәт юк. Син имтиханыңны уңышлы үттең. Аның урынына шушы тәкәне чал!» – ди кебек. Шулай итеп, күпме Исмәгыйльләр урынына куйлар корбан ителгән һәм ителә. Димәк, корбан чалганда бу мәгънәләрне истә тоту бик мөһим. Корбан чалганда, ошбу фидакарьлек тойгысын саклау ихлас һәм самимилегебез күрсәткече булыр.

**5. КОРБАН – ТӘКЪВА.**

Бер Аллаһның ризалыгын гына күздә тотып чалынган корбан тәкъвага илткән мөһим бер чарадыр. Коръән Кәримдә Җәнабы Хак болай боера: «Аларның итләре дә, каннары да Аллаһка бармас, Аңа фәкать сезнең тәкъвагыз гына ирешер. Менә шулай итеп (Аллаһ әлеге корбанлык хайваннарны) сезнең файдалануга тапшырды, бәс һидаять юлына бастырганы өчен Аллаһны олуглагыз! (Әй Расүлем!) Игелек ияләрен сөендер!» (Хаҗ, 37). Янә Коръәннең: «(Һабил Кабилгә) болай дигән иде: Аллаһ бары тәкъва ияләренең гамәлен генә кабул боерыр,» (Маидә, 27) аятендә гамәлнең кабуллыгында төп шарт тәкъвалык икәне, тәкъвалылар гына Аллаһ катында мәкъбүл гамәлгә ирешә алганы искәртелә. Шуңа күрә, корбанны ит һәм тире дип түгел, безне чиксез кодрәт иясе Олуг Раббыбызга кавыштырган форсат дип карарга кирәк.

**6. КОРБАН – РӘХМӘТ ҺӘМ БӘРӘКӘТ.**

Бик күп фәкыйрьләр нәкъ менә Корбан бәйрәмендә, бер кабым иткә тилмергән сабыйларын кинәндерәләр. Чалынган миллионнарча корбанның итләре, тиреләре, эчәгеләре, башлары һәм башка әгъзалары бик күпләрнең ихтыяҗларын киметә төшә. Шул рәвешле, корбан һәрьяклап хәер вә бәрәкәткә сәбәп була.

**7. КОРБАН – СӘҮДӘ ҺӘМ ИКЪТИСАДКА ЯРДӘМ.**

Корбан вакытында икътисади тормыш җанлана төшә. Корбанга дип терлек симертүчеләр, аны алучы, сатучы, ташучы һәм чалучылар, тире эшкәртүче, итче һәм терлек азыгы җитештерүчеләр бу уңайдан акча эшләп, ризыгын тәэмин итә.

ИхлаС

Подписано в печать 05.11.2009.
Формат 60x84 $^{1}/_{16}$. Офсетная бумага. Гарнитура «Arial».
Ус.печ. листов 1,75. Заказ 118/09. Тираж 1000 экз.

Издательство «Ихлас». 420066, Казань, Декабристов, 2. Тел.: 519-45-29.
*e-mail*: izd-ihlas@rambler.ru

Отпечатано с готового оригинал-макета в типографии ООО ПИК «Дом печати».
420126, Казань, пр.Ф.Амирхана, 12а.
Тел/факс: (843) 520-17-74, 520-17-65. e-mail: house-pr@mail.ru